**Республика Татарстан**
**Совет Старо-Имянского сельского поселения**
**Сармановского муниципального района**
423373, с. Старый Имян,
ул. М. Вахитова,36 в

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы**
**Иске Имэн авыл жирлеге Советы**
423373, Иске Имэн авылы,
М. Вахитов урамы, 36 в йорт

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 09» декабрь 2016 ел № 38

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы " Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау нигезләре турында "2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2016 елның 29 сентябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Иске Имән авыл җирлеге уставын гамәлдәге закон нормалары белән китерү максатларында **Совет карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 10 номерлы карары белән кабул ителгән, түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:
1) 7.1 статьяның 1 өлешен (авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә хокуклары) түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:
14) "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында"Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.
2) 28 статьяның 1 өлешен (җирлек Советы компетенциясе) түбәндәге эчтәлекле 38 пункт өстәргә: 38) җирлек территориясен төзекләндерү һәм җирлек территориясен карап тоту кагыйдәләрен раслау.
3) 43 статьяның 2 өлешен (Башкарма комитет вәкаләтләре) түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

14) "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында"Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыра.
2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы «муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында» Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советы рәисе Р. А. Исламова